МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное образовательное учреждение
высшего образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая

УТВЕРЖДАЮ
Проректор по образовательной деятельности КФУ
Проф. Д.А. Таюрский
_______________ «___»________20__г.

*подписано электронно-цифровой подписью*

# Программа дисциплины

Татарское устное народное творчество Б1.Б.15.10

Направление подготовки: 45.03.01 - Филология
Профиль подготовки: Прикладная филология: татарский язык и литература, журналистика
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский

**Автор(ы):**
Замалиева Л.Ф.
**Рецензент(ы):**
Закирзянов А.М.

**СОГЛАСОВАНО:**

Заведующий(ая) кафедрой: Сайфулина Ф. С.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г

Учебно-методическая комиссия Института филологии и межкультурной коммуникации (Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No 9023116619


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины

2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы

3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

7. Литература

8. Интернет-ресурсы

9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану

Программу дисциплины разработал(а)(и) доцент, к.н. (доцент) Замалиева Л.Ф. кафедра татарской литературы Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая , Luiza.Zamalieva@kpfu.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

Главная цель курса - ознакомить студентов богатой системой родов и видов национального фольклора, приобщить их к ценностям духовной культуры всего народа, являющейся средоточием родного языка, разнообразных жанров и полноценных произведений устного творчества. Другая же не менее важная цель - подготовить будущих специалистов к профессиональной деятельности: навыкам и формам использования полученных теоретическо-прикладных знаний на практике, в своей будущей работе.

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел "Б1.Б.15 Дисциплины (модули)" основной образовательной программы 45.03.01 Филология и относится к базовой (общепрофессиональной) части. Осваивается на 1 курсе, 1 семестр.

Дисциплина 'Татарское устное народное творчество' входит как составная часть в раздел учебного цикла Б.3, В.9 ФГОС-3. Общепрофессиональная вариативная часть направления подготовки 45.03.01. Филология: Татарский язык и литература, журналистика.

Данная дисциплина является необходимой базой для изучения и углубленного освоения истории татарской литературы.

Дисциплина изучается в I семестре.

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ОК-2 (общекультурные компетенции) | Способность анализировать основные этапы и закономерности исторического развития общества для формирования гражданской позиции |
| ОК-7 (общекультурные компетенции) | способностью к самоорганизации и самообразованию |
| ОПК-1 (профессиональные компетенции) | способностью демонстрировать представление об истории, современном состоянии и перспективах развития филологии в целом и ее конкретной (профильной) области |
| ОПК-3 (профессиональные компетенции) | способностью демонстрировать знание основных положений и концепций в области теории литературы, истории отечественной литературы (литератур) и мировой литературы; представление о различных жанрах литературных и фольклорных текстов |
| ОПК-4 (профессиональные компетенции) | владением базовыми навыками сбора и анализа языковых и литературных фактов, филологического анализа и интерпретации текста |



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ПК-1 (профессиональные компетенции) | способностью применять полученные знания в области теории и истории основного изучаемого языка (языков) и литературы (литератур), теории коммуникации, филологического анализа и интерпретации текста в собственной научно-исследовательской деятельности |
| ПК-2 (профессиональные компетенции) | владение базовыми навыками сбора и анализа языковых и литературных фактов с использованием традиционных методов и современных информационных технологий |
| ПК-3 (профессиональные компетенции) | владением навыками подготовки научных обзоров, аннотаций, составления рефератов и библиографий по тематике проводимых исследований, приемами библиографического описания; знание основных библиографических источников и поисковых систем |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

основных положений в области теории и истории фольклора, филологического анализа и интерпретации вербального и письменного текста

2. должен уметь:

демонстрировать знание основных положений в области теории и истории фольклора, филологического анализа и интерпретации вербального и письменного текста

3. должен владеть:

Владеть базовыми знаниями о народном творчестве и культурой системного мышления, способностью использовать основные положения и методы фольклористики в профессиональной деятельности.

4. должен демонстрировать способность и готовность:

Студент должен уметь демонстрировать знание основных положений в области теории и истории фольклора, филологического анализа и интерпретации вербального и письменного текста

### 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

Общая трудоемкость дисциплины составляет 2 зачетных(ые) единиц(ы) 72 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины: зачет в 1 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

**Тематический план дисциплины/модуля**


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практи-ческие занятия | Лабора-торные работы | |
| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
| | | | | Лекции | Практи-ческие занятия | Лабора-торные работы | |
| 1. | Тема 1. Фән буларак "Татар халык авыз иҗаты" Аңа хас төп үзенчәлекләр | 1 | 1 | 1 | 0 | 0 | Реферат |
| 2. | Тема 2. Мифология | 1 | 2 | 2 | 2 | 0 | |
| 3. | Тема 3. Йола фольклоры (ырымнар, календарь йола иҗаты, гаилә йолалары) | 1 | 3-5 | 4 | 3 | 0 | |
| 4. | Тема 4. Эпик жанрлар (әкиятләр, риваять һәм легендалар, эпослар) | 1 | 6-9 | 4 | 4 | 0 | Письменная работа |
| 5. | Тема 5. Лирик жанрлар (җырлар, такмаклар) | 1 | 10-13 | 3 | 4 | 0 | Письменная работа |
| 6. | Тема 6. Лиро-эпик һәм лирик жанрлар (бәетләр, тарихи җырлар) | 1 | 14-17 | 3 | 4 | 0 | |
| 7. | Тема 7. Балалар фольклоры | 1 | 17 | 1 | 1 | 0 | |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 1 | | 0 | 0 | 0 | Зачет |
| | Итого | | | 18 | 18 | 0 | |

**4.2 Содержание дисциплины**

**Тема 1. Фән буларак "Татар халык авыз иҗаты" Аңа хас төп үзенчәлекләр**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

1. Фольклор төшенчәсенә билгеләмә. Халык иҗаты, халык әдәбияты терминнары. 2. Халык авыз иҗатына хас төп үзенчәлекләр. 3. Фольклорның башка фәннәр белән бәйләнеше. Халык иҗаты ул- халык вәкилләре тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар буе халык хәтерендә сакланып килгән чәчмә һәм шигъри әсәрләр җыелмасы. Халыкара практикада халык иҗатын билгеләү өчен фольклор атамасы да кулланыла. Фольклор сүзе 1846 елда галим Вильям Томс тарафыннан фәнгә кертелгән халыкара термин. Ул ике өлештән тора: folk - халык, lore - акыл, хикмәт дигәнне аңлата. Димәк, фольклор сүзен шартлы рәвештә халык акылы, халык хикмәте дип тәрҗемә итәргә мөмкин. XX гасыр башында бездә халык иҗатына карата халык әдәбияты термины кулланыла. Г.Тукай халык җырлары турында 1910 елда Шәрык клубында укыган лекциясен "Халык әдәбияты" дип атый. Әдәбият галиме Гали Рәхим 1914 елда "Халык әдәбиятымызга бер караш" дип аталган мәкаләсен бастыра. 20 еллар уртасыннан фольклор, 30 нчы еллардан халык иҗаты термины да әйләнешкә кереп китә. Фольклор терминына синоним буларак хәзер халык сүз сәнгате, халыкның поэтик иҗаты, халык авыз (тел) иҗаты атамалары да кулланыла. Фольклорның төп үзенчәлекләренең берсе - аның телдән иҗат ителүе белән бәйле. Шуңа да без аны икенче төрле халыкның авыз иҗаты дип атыйбыз. Бу үзенчәлек бик борынгы, әле язу булмаган ук чорлардан килә. Ул вакытларда мифология һәм фольклор, халыкның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерүче бердәнбер иҗат төре буларак җәмгыять тормышында әһәмиятле роль уйнаган. Әмма бу һич кенә дә язу барлыкка килү белән фольклор юкка чыга икән дигән сүз түгел. Чөнки язма мәдәният башлангыч чорда үзе дә халык иҗатына таяна.

**Тема 2. Мифология**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

XX нче гасыр ахыры - XX1 нче гасыр башы татар әдәбиятында чынбарлыкы сурәтләүгә дини мистик һәм мифологик күзаллаулар белән сугарылган әдәби әсәрләр мәйданга чыкты. Хәзерге вакытта мифның 500дән артык билгеләмәсе бар. Мифология (грекча"миф"-сүз,хикәят.)-борынгыларның дөнья, тирәлек турындагы фантастик күзаллаулары һәм хыялда туган фантастик образлар, персонажлар турындагы хикәятләре (мифлар) җыелмасы. Теоретик нигезләмәләр өчен А. Ф. Лосев фикерләре аерым игътибарга лаек. Мифларга билгеләмә бирер өчен багышланган классик хезмәтләрдәге билгеләмә белән генә чикләнергә туры килә: "Миф (сүзнең туры мәгънәсендә)-ул хикәяләү, чынбарлыкны фантастик рәвештә гәүдәләндергән "хикәяләрнең" җыелмасы, әмма бу сүз сәнгате жанры түгел, ә бәлки дөньяны билгеле бер күзаллау .

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

1. Ырымнар. Аларның магик табигате. Жанрның үзенчәлекләре. Ырымнарны төркемләү. Ак һәм кара ырымнар. Дәвалау ырымнары яки им-томнар. Хуҗалык ырымнары. Иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләрне җайга салуга юнәлтелгән ырымнар. 2. Ырым текстларының төзелеше, поэтикасы һәм стиле. Ырымнарны җыю һәм өйрәнү тарихы. Ырымнарның мифология белән турыдан-туры бәйләнеше. 3. Фаллар. Магик йола белән ырым традицияләре очрашкан урында туган булырга тиеш дип фаразланган жанр булуы. Фал ачтыруның сәбәпләре. Татарлардагы фал ачу ысуллары. Фал ачу урыннары. Ырымнарның йола фольклорындагы урыны. 4. Сез яшәгән төбәктә им-том белән шөгыльләнүче кешеләр бармы? Ырым текстлары язып килегез.

**Тема 3. Йола фольклоры (ырымнар, календарь йола иҗаты, гаилә йолалары)**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

1. Йола төшенчәсенә аңлатма. 2. Йоланың гадәттән аермасы. 3. Йолаларны классификацияләү. ола фольклоры - халык иҗатының иң борынгы төрләреннән берсе. Кешеләр, хезмәт процессында туган тәҗрибәләре нигезендә, табигать көчләрен буйсындыру турында бик күптәннән бирле хыялланганнар. Ләкин табигать серләрен, аның үзгәрешләрен һәм сәбәпләрен төшенерлек аң-белемнең булмавы аркасында, кешеләр табигатькә буйсынырга, табынырга мәҗбүр булганнар. Шул ук вакытта кешеләрнең аралашулары һәм билгеле бер дәрәҗәдә тормышка материалистик карый башлаулары аларда табигать көчләреннән ничек булса да файдалану теләген тудырган. Кеше үзенең тормышы өчен кирәк булган төрле нәрсәләрне табигатьттән сорау һәм үтенү аркасында табигать көчләренә багышланган магик йолалар килеп чыккан. Борынгы кешеләр сүзнең, арбауның, ырымнарның, җыр-сүз тезмәләренең магик көченә ышанганнар. Гомумән алганда, йола поэзиясенең барлык жанрлары, төрләре нигезендә беркатлы һәм шиксез ышану ята һәм барлык шигъри үзенчәлекләрне билгели. Йола ул - аерым бер коллективның яисә кешенең иҗтимагый-хуҗалык һәм шәхси тормышындагы иң җитди моментларда башкарыла торган, борынгыдан килгән традицион хәрәкәт- гамәлләре. Йола белән гадәт арасында аерма бармы? Гадәт ул киләчәк буыннарга мәдәниятны җиткерүнең үзенә бер традицион формасы. Ләкин аның йоладан аермасы шунда, ул максатка ярашлы хәрәкәтләрне киләчәк буыннарга җиткерә: хезмәт эшчәнлеге белән бәйле хәрәкәтләр, көнкүрештәге, гаиләдәге хәрәкәтләр. Мондый хәрәкәтләр нинди дә булса нәтиҗәгә ирешү өчен хезмәт итә. Йоланың гадәттән төп аермасы шунда, ул үз эченә турыдан-туры максатка ярашлы хәрәкәтләрне түгел, ә бәлки символик хәрәкәтләрне туплый. Халык йолалары белән бәйле шигъри әсәрләрне икегә бүлеп карыйлар: 1. Ел фасыллары дәвамында башкарыла торган хуҗалык эшләренә бәйле календарь йолалар һәм 2. Гаилә йолалары.

***практическое занятие (3 часа(ов)):***

1. Бала туу белән бәйле, никах туе, кешене соңгы юлга озатуга мөнәсәбәтле йолалар комплексы, кузайтын (каршы алу), хәрби хезмәткә озату һ.б. бәйрәмнәр; аларны үткәрү максатлары, аларның вазифалары. 2. Дини йолаларның килеп чыгышы, үткәрү әһәмияте. Ислам дине йолаларының бүгенге көндә сакланышы. Гаилә йолаларына диннең йогынтысы. 3. Йола фольклорының милли тәрбия нигезе буларак роле, ?Халык педагогикасы? дәресләрендә кулланылышы.

**Тема 4. Эпик жанрлар (әкиятләр, риваять һәм легендалар, эпослар)**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

1. Дастан төшенчәсенә билгеләмә. 2. Дастаннарны барлыкка килү тарихы. 3. Дастаннарны классификацияләү. 4. "Идегәй" дастаны. Дастан - данлау, кемнәрнеңдер исемен, ниндидер вакыйгаларны, язмышларны халык күңеленә язып куеп, киләчәк буыннар хәтеренә җиткерү, тарихта калдыру дигән сүз. Дастан - төрки һәм фарсы фольклорында һәм әдәбиятларындагы эпик характердагы әсәр. Икенче төрле аларны эпос дип тә атыйлар. Эпос (грекчадан, сүз, сөйләм, хикәяләү мәгънәсендә) төшенчәсенең фольклористикада һәм әдәбият белемендә киң һәм тар мәгънәләре бар. Беренчедән ул вакыйгалылыкка, хикәяләүгә нигездәнгән әдәби төрне белдерә һәм шушы сыйфатларга ия булган төрле әдәби һәм фольклор жанрларын үз эченә ала. Тар мәгънәдә кулланылганда исә әкияти-мифологик һәм героик яки романтик планда хикәяләүче фольклор жанрына, шулай ук халык эпосы йогынтысында формалашкан әдәби әсәрләргә карата кулланыла.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

Әкият ? халык авыз иҗатының борынгы, шул ук вакытта киң таралган һәм мавыктыргыч жанрларның берсе. Әкиятләрдә халыкның күп гасырлык тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, яхшылык һәм явызлык турындагы төшенчәләре тупланган, киләчәккә өмет һәм хыяллары чагылган. Әкият явызлыкны гаепли, гаделлекне, хаклыкны яклый, кешеләрне игелекле, тугры һәм мәрхәмәтле булырга өйрәтә. Чын мәгънәсендәге әкиятнең туу вакыты ? ул нәкъ менә изге хикәянең (әкият ?баба?сының) нәфис хикәягә әверелеп киткән чагы. Бу хәл исә изге хикәянең ритуалдан аерылуы нәтиҗәсендә була. Чөнки йоланы барлыкка китергән шартлар вакытлар узу белән бетә (аларның иң мөһиме ? аучылыкның бердәнбер яки төп яшәү чыганагы булудан туктавы). Бу исә, үз чиратында, әүвәлге изге мәгънәдәге йоланың да бетүенә китерә. Йоладан аерылган хикәя шулай ук үзенең ?изге?леген җуя һәм барлык кешеләр өчен дә сөйләнелә башлый. Әкиятнең шушы рәвешчә мөстәкыйль жанр булып формалашып җитүе борынгы община строеның таркалу чорына туры килә. Менә шул чордан башлап, әкият гамәллилектән арына һәм беренче чиратта эстетик вазифа үти башлый. Әлбәттә, аның идея вазифасы да (әхлакый, социаль һ.б.) мөһим урын тота [Җамалетдинов, 1981]. ?Әкият? дигән сүз гарәпчә хикәят сүзенең фонетик яктан үзгәрүе нәтиҗәсендә барлыкка килгән. өлкән буын вәкилләре арасында әкиятне хикәят дип атаучылар әле бүген дә очрый. Әкият ? фольклорда катлаулы күренеш. Әкияткә билгеләмә түбәндәгечә: әкият ? ул халык поэтик авыз иҗатының төп жанрларыннан берсе булып, уйдырмага таянган, тылсымлы, маҗаралы яисә көнкүреш характерындагы эпик, башлыча чәчмә сәнгать әсәре. Фәнни-тикшеренү максатларында әкиятләр күп халыкларда нигездә өч төргә бүлеп карала: ? хайваннар турындагы әкиятләр; ? тылсымлы әкиятләр; ? көнкүреш әкиятләре.

**Тема 5. Лирик жанрлар (җырлар, такмаклар)**

***лекционное занятие (3 часа(ов)):***

1. Җыр төшенчәсенә билгеләмә. 2. Җырларны өйрәнү тарихыннан. 3. Татар халык җырларын классификацияләү. 4. Йола җырлары. 5. Тарихи җырлар. 6. Уен-бию җырлары. 7. Лирик җырлар. Җыр - сүз-текст белән көй-музыканың үзара үрелүенә нигезләнгән, җырлап башкаруны күздә тотып иҗат ителгән әсәр. Функцияләренә, иҗтимагый вазифаларына бәйле рәвештә татар халык җырлары дүрт жанр төркеменә бүленә: йола җырлары, тарихи җырлар, уен һәм бию җырлары, лирик җырлар.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

1. Йола җырлары. Календарь йолалар белән бәйле җырлар. Гаилә йолалары белән бәйле җырлар (туй йоласы җырлары). 2. Лирик җырларның тематик төрлелеге: социаль тормыш, хәсрәтле дөнья турында, читкә китеп бәхет эзләүчеләргә, хатын-кызның авыр язмышына багышланган җырлар, мәхәббәт җырлары, дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары. Лирик озын һәм кыска җырлар. Аларның поэтик табигате. Лирик җырларда традицион образлар. 3. Жанрның уен үзенчәлегенә бәйле төрләре: кара-каршы тезелеп яки парлашып башкарыла торган җырлар (Җимчәчәк, Челтәр элдем читәнгә, Чума үрдәк, чума каз); әйлән-бәйлән яки түгәрәк җырлары (Ай йолдызым, И дүдәме, дүдәме, Их, су алулары, Кәрия-Зәкәрия, Наза, Уфа-Чиләбе), һөнәр күрсәтү уеннарына бәйле җырлар (Җыр әйтешү, Ялтыр-йолтыр, Сөясеңме-сөймисеңме? ) 4. Уен-бию җырларының такмак жанры белән керешеп китүе, уен һәм бию такмаклары (Әпипә, Әнисә, Бие-бие, Хәйбулла, Бас-бас, каты бас һ.б.).

**Тема 6. Лиро-эпик һәм лирик жанрлар (бәетләр, тарихи җырлар)**

***лекционное занятие (3 часа(ов)):***

Бәет - нигезенә кайгылы яки көлкеле вакыйга салынган, татар халык иҗатының лиро-эпик жанры. Бәет тормышта булып узган вакыйгаларны суынмаган эзләреннән тасвирлый. Шуңа күрә ул хис-кичерешләрнең иң киеренке вакытларында туа. "Бәет" атамасы гарәп телендә ике юллык строфа төрен белдерүче "бәйт" сүзеннән алынган дип исәпләнелә. Бәет жанры фаҗигале һәм героик вакыйгалар, шулай ук гыйбрәтле һәм гадәттән тыш хәлләр уңае белән чыгарылган әсәрләрне берләштерә. Аларның тексты шигъри формада була һәм телдән әйтелә яки көйләп башкарыла. Ләкин көйләп башкарылган бәетләргә карата да халыкта "бәет җырлау" дигән гыйбарә кулланылмый, ә "көйләп бәет әйтү" яки "көйләп бәет уку" диләр. Бу, күрәсең, әлеге жанрның "язма китап культурасы" һәм электән килгән "көйләп китап уку" традициясе белән бәйләнештә туганлыгын күрсәтүче бер дәлил

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

1. Бәет жанрына билгеләмә бирергә, төркемчәләрен санарга, мисаллар белән дәлилләргә. 2. Үзегезнең төбәктә иҗат ителгән бәет текстларын язып алып килергә. 3. Җыелган бәетләрне укып, анализлап, тематик бүленешкә нигезләнеп таблицалар тутырырга. 4. Соңгы елларда иҗат ителгән бәетләрнең поэтик үзенчәлекләрен чагыштырма планда тикшерергә (алдан бирелгән бәет текстлары нигезендә). 5. Мөнәҗәтләр, аларның тематик төркемчәләре. 6. Мөнәҗәтләрнең поэтик үзенчәлекләре.

**Тема 7. Балалар фольклоры**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

Балалар фольклоры. Татар балалр фольклорын өйрәнүнең тарихы. Бу өлкәдә Н.Исәнбәт, Р.Ягъфәров, Ф.Ибраһимова хезмәтләре. Балалар фольклорын төркемләү. Бала багу поэзиясе. Балалар өчен иҗат ителгән әсәрләр. Уеннар

***практическое занятие (1 часа(ов)):***

Бүгенге көндә балалар фольклорының яшәеше. 1. Бармак уеннары. 2. Хәрәкәтле уеннар. 3. Такмак-такмазалар. 4. Хәрәтле уеннар. 5. Санамышлар.

### 4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)

| N | Раздел дисциплины | Се-местр | Неде-ля семе стра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудо-емкость (в часах) | Формы контроля самосто-ятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тема 1. Фән буларак "Татар халык авыз иҗаты" Аңа хас төп үзенчәлекләр | 1 | 1 | подготовка к реферату | 12 | Реферат |
| 4. | Тема 4. Эпик жанрлар (әкиятләр, риваять һәм легендалар, эпослар) | 1 | 6-9 | подготовка к письменной работе | 12 | Письмен-ная работа |
| 5. | Тема 5. Лирик жанрлар (җырлар, такмаклар) | 1 | 10-13 | подготовка к письменной работе | 12 | Письмен-ная работа |
| | Итого | | | | 36 | |

## 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

Рекомендуемые образовательные технологии: лекции, практическая работа, тестирование, контрольные работы, самостоятельная работа, курсовая работа (по выбору).

При проведении аудиторных занятий намечаются использовать активные и игровые формы обучения (деловые и ролевые игры, собеседование о занимательном фольклоре, организация диспутов, анализ конкретных произведений и разбор докладов своих сокурсников) в соответствии с внеаудиторной работой. Удельный вес такого типа занятий или форм обучения определяться исходя из характера тем и особенностей содержания курса.

## 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

**Тема 1. Фән буларак "Татар халык авыз иҗаты" Аңа хас төп үзенчәлекләр**

Реферат , примерные вопросы:

1. К.Насыйриның татар фольклорын үстерүдәге роле. 2. В.В.Радлов һәм аның татар халык иҗатына бәйләнешле хезмәтләре. 3. Х.Бәдигыйның татар фольклорын үстерүгә керткән өлеше 4. Ф.Туйкинның фольклорга караган хезмәтләре 5. Г.Рәхимнең татар фольклорын үстерүдәге роле. 6. Г.Тукайның фольклористика өлкәсендәге эшчәнлеге. 7. Г.Бәшировның татар фольклорын җыю һәм бастыру өлкәсендәге эшчәнлеге. 8. Н.Исәнбәтнең татар фольклорына караган хезмәтләре. 9. Хәмит Ярми - беренче профессиональ татар фольклорчысы. 10. М.Бакировның халык авыз иҗатын өйрәнүгә багышланган хезмәтләре.

**Тема 2. Мифология**

**Тема 3. Йола фольклоры (ырымнар, календарь йола иҗаты, гаилә йолалары)**

**Тема 4. Эпик жанрлар (әкиятләр, риваять һәм легендалар, эпослар)**

Письменная работа , примерные вопросы:

Форма контроля: письменная работа I вариант 1. Татар фольклорында жанрлар системасы. 2. Борынгы фикерләү төре буларак анимизм. II вариант 1. Фольклорның гомуми үзенчәлекләре. 2. Борынгы фикерләү төре буларак антропоморфизм. III вариант 1. Борынгы сәнгати синкретизм һәм фольклорның синтетик табигате. 2. Төрки-болгар-татар мифологиясе. IV вариант 1. Фольклорда миллилек. 2. Борынгы фикерләү төре буларак магизм. V вариант 1. Сәнгатьнең барлыкка килеү турында теорияләр. 2. Борынгы фикерләү төре буларак фетишизм. VI вариант 1. Миф һәм мифология турында төшенчә. Мифларның вазыйфа-функцияләре һәм төрләре. 2. Борынгы фикерләү төре буларак тотемизм. VII вариант 1. Ырым жанры турында төшенчә. Ырымнарның төрләре. 2. Календарь йола иҗаты һәм жанрлары. Икенче контроль эш I вариант 1. Тылсымлы әкиятләрнең жанр үзенчәлекләре, идеаллаштырылучы геройлары. 2. Табышмаклар, аларның төрләре, төзелеше. II вариант 1. Риваять һәм легендаларның уртак яклары һәм аермалары. 2. Туй йола жанрлары. III вариант 1. Мәкаль һәм әйтемнәрнең уртак һәм аемалы яклары. 2. Лирик җырларның жанр сыйфатлары, төрләре. IV вариант 1. "Чура батыр" дастаны һәм аның тарихи җирлеге. 2. Тарихи җырларның жанр сыйфатлары һәм төрле чорларга бәйләнешле үрнәкләре. V вариант 1. Бәетләрнең жанр сыйфатлары, төрләре, үрнәкләре. 2. Тылсымлы әкият герое белән героик дастан каһарманы арасында уртак һәм аермлы сыйфатлары. VI вариант 1. Героик эпос-дастан төрләре. "Идегәй" дастаны. 2. Уен-бию җырлары һәм такмаклар. Аларның төрләре. VII вариант 1. Мөнәҗәтләрнең жанр сыйфатлары, төрләре. 2. Көнкүреш әкиятләренең жанр үзенчәлекләре, конфликт төрләре һәм геройлар.

**Тема 5. Лирик жанрлар (җырлар, такмаклар)**

Письменная работа , примерные вопросы:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Тема: Лирические жанры (лирические песни, игрово-плясовые песни, такмаки, анекдоты) 1. Йола җырлары. Календарь йолалар белән бәйле җырлар. Гаилә йолалары белән бәйле җырлар (туй йоласы җырлары). 2. Лирик җырларның тематик төрлелеге: социаль тормыш, хәсрәтле дөнья турында, читкә китеп бәхет эзләүчеләргә, хатын-кызның авыр язмышына багышланган җырлар, мәхәббәт җырлары, дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары. Лирик озын һәм кыска җырлар. Аларның поэтик табигате. Лирик җырларда традицион образлар. 3. Жанрның уен үзенчәлегенә бәйле төрләре: кара-каршы тезелеп яки парлашып башкарыла торган җырлар ("Җимчәчәк", "Челтәр элдем читәнгә", "Чума үрдәк, чума каз"); әйлән-бәйлән яки түгәрәк җырлары ("Ай йолдызым", "И дүдәме, дүдәме", "Их, су алулары", "Кәрия-Зәкәрия", "Наза", "Уфа-Чиләбе"), һөнәр күрсәтү уеннарына бәйле җырлар (Җыр әйтешү, "Ялтыр-йолтыр", "Сөясеңме-сөймисеңме?" ) 4. Уен-бию җырларының такмак жанры белән керешеп китүе, уен һәм бию такмаклары ("Әпипә", "Әнисә", "Бие-бие", "Хәйбулла", "Бас-бас, каты бас" һ.б.). 5. Бәет жанрына билгеләмә бирергә, төркемчәләрен санарга, мисаллар белән дәлилләргә. 6. Үзегезнең төбәктә иҗат ителгән бәет текстларын язып алып килергә. 7. Җыелган бәетләрне укып, анализлап, тематик бүленешкә нигезләнеп таблицалар тутырырга. 8. Соңгы елларда иҗат ителгән бәетләрнең поэтик үзенчәлекләрен чагыштырма планда тикшерергә (алдан бирелгән бәет текстлары нигезендә). 9. Мөнәҗәтләр, аларның тематик төркемчәләре. 10. Мөнәҗәтләрнең поэтик үзенчәлекләре.

**Тема 6. Лиро-эпик һәм лирик жанрлар (бәетләр, тарихи җырлар)**

**Тема 7. Балалар фольклоры**

**Итоговая форма контроля**

зачет (в 1 семестре)

Примерные вопросы к итоговой форме контроля

1. Фән буларак фольклористика, аның үзенчәлеге, бурычлары.
2. Татар халык авыз иҗатының тармаклары. Аларның үзара бәйләнеше. Үзенчәлекләре.
3. Фольклор әсәрләрендә синкретизм, татар халык авыз иҗатының милли үзенчәлекләре.
4. Татар фольклористикасын фәнни җирлектә өйрәнү. Фольклористика өлкәсендә эшләгән күренекле әдипләрнең һәм галимнәрнең (К.Насыйри, Н.Исәнбәт, Г.Бәширов, Х.Ярми, Ф.Урманчеев, Х.Мәхмүтов һ.б.) хезмәтләре.
5. Татар халык авыз иҗатының язма әдәбият белән бәйләнеше.
6. Татар халык авыз иҗатын өйрәнүдә Каюм Насыйриның эшчәнлеге.
7. Татар халык иҗатын өйрәнүдә Габдулла Тукайның эшчәнлеге. Шагыйрьнең "Халык моңнары", "Халык әдәбияты" хезмәтләре, фольклорга нигезләнгән әсәрләре.
8. Татар халык авыз иҗатын өйрәнүдә Нәкый Исәнбәт эшчәнлеге.
9. Татар халык йолалары, аларның төрләре, йола иҗатының тәрбияви әһәмияте, сәнгатьчә үзенчәлеге.
10. Татар халкының туй йолалары. Аларның сәнгатьчә үзенчәлеге.
11. Татар халкының бүгенге йолалары, аларның тәрбияви әһәмияте: Сабан туйлары, аларны үткәрү тәртибе.
12. Татар халык иҗатында гаилә һәм көкүреш йолалары, аларның дини йолалар белән мөнәсәбәте һәм үзара бәйләнеше.
13. Татар халык иҗатында календарь йолалар һәм аларның поэзиясе.
14. Өмә поэзиясе, аларны оештыру һәм үткәрү тәртипләре.
15. Әкиятләр. Аларны төркемләү. Әкиятләрне җыю һәм өйрәнү тарихы. Әкиятләрнең сәнгатьчә эшләнеше.
16. Татар халык әкиятләрендә традицион алымнар. "Камыр батыр" әкиятенә анализ.
17. Әкиятләрдә традицион образлар. "Таңбатыр" әкиятенә анализ.
18. Көнкүреш әкиятләре. Аларны төркемләү. "Зирәк карт", "Саран белән юмарт" әкиятләренә анализ.
19. Тылсымлы әкиятләр. Аларның тематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше.

20. Татар халык җырлары. Кыска һәм озын лирик җырлар, аларның тематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше.
21. Тарихи җырлар, аларның тематикасы. "Кара урман", "Көзге ачы җилләрдә", "Ком бураны" җырларына поэтик анализ.
22. Татар халык җырларын җыю һәм өйрәнүдә И.Надиров, К.Миңнуллин, Җ.Фәйзи, А.Ключарев, М.Нигъмәтҗәнов, З.Сәйдәшева, Р.Исхакова-Вамба хезмәтләре.
23. Татар халык иҗатында дуслык, туганлык, мәҗлес җырлары. "Дусларым, дус ишләрем", "Ак калфак" җырларына поэтик анализ.
24. Уен җырлары. Аларның тематикасы, художество үзенчәлеге. "Ак калач", "Күгәрчен", "Төймә", "Челтәр элдем читәнгә" җырларына поэтик анализ.
25. Татар халкының шаян җырларына ("Сания апа", "Башмагым", "Җизнәкәй", "Өй артында егет килгән") поэтик анализ.
26. Татар халык иҗатында дастаннар. Аларның тематикасы һәм сәнгатьчә эшләнешләре. Алыплар турындагы дастаннар.
27. Дастаннарда традицион алымнар. Тарихи дастаннар.
28. "Идегәй" дастанын туплау, өйрәнү һәм бастырып чыгару тарихы.
29. "Идегәй" дастанында тарихи чынбарлык һәм мифология. Төп геройларга анализ.
30. Мәхәббәт дастаннары. Аларның сәнгатьчә эшләнеше. Берәр дастанга поэтик анализ.
31. Болгар дәүләте чоры легендалары: "Янмый торган кыз", "Хан кызы Алтынчәч", "Ак бүре ыруы" легендаларына анализ.
32. Татар халык легендаларының поэтик эшләнеше. "Зөһрә кыз", "Ана йөрәге", "Алып тавы" легендаларына анализ.
33. Риваятьләр, аларның үзенчәлеге. Казан ханлыгы чорында һәм аннан соң милли изүгә каршы иҗат ителгән риваятьләр. "Казан кайда корылган?", "Сөембикә", "Шәриф Кол", "Бәхтияр Канкаев", "Пугачев хакында..." риваятьләре.
34. Авыллар тарихы белән бәйле топонимик риваятьләр.
35. Төрки-татар мифологиясендә башка халыклар белән уртаклыклар һәм милли үзенчәлекләр.
36. Мифологик хикәятләр һәм мифик образлар.
37. Татар халык иҗатында бәетләр. Аларның төрләре, сәнгатьчә эшләнешләре.
38. "Сак-сок бәете", аның эчтәлеге, сәнгатьчә эшләнеше.
39. Татар халык иҗатында мөнәҗәтләр. Аларның төрләре, поэтик эшләнеше, халыкта яшәү һәм башкарылу үзенчәлеге.
40. Татар халкының афористик иҗат төрләре. Аларның сәнгатьчә үзенчәлекләре, тәрбияви әһәмиятләре, өйрәнелү тарихы.
41. Мәкаль һәм әйтемнәр. Аларны тематик яктан төркемләү. Мәкаль-әйтемнәрнең сәнгатьчә эшләнеше.
42. Табышмаклар. Аларны төркемләү. Табышмакларның сәнгатьчә үзенчәлеге.
43. Сынамышлар. Аларның функциясе, эчтәлеге.
44. Мәзәкләр. Мәзәкләрнең төзелеше, төрләре, сәнгатьчә эшләнеше. Мәзәкләрне өйрәнүнең торышы.
45. Хуҗа Насретдин мәзәкләре. Аларның тематикасы, сәнгатьчә эшләнеше.
46. Халык уеннарының үзенчәлеге. "Йөзек салыш", "Сукыр тәкә", "Кем сукты?" кебек уеннарны башкару тәртибе, аларның тәрбияви әһәмияте.
47. Балалар фольклоры. Аның халык педагогикасы белән бәйләнеше. Бала багу поэзиясе. Бишек җырлары, кузгаткычлар, мавыктыргычлар.
48. Балалар фольклорын төркемләү, аның принциплары. Балалар фольклорының жанр төрлелеге, тел-сурәтләү чаралары. Бу өлкәдә эшләгән галимнәр.
49. Балачак поэзиясе. Эндәшләр, үртәвечләр, санамышлар, аларның поэтик төзелеше.
50. Балалар фольклорында такмаклар, такмазалар. "Әнисә", "Чат-чат" такмакларына һәм "Бай" такмазасына анализ.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

51. Балалар уеннары, аларның төрләре һәм үзенчәлеге. Балалар уеннарында синкретизм.

52. Балалар фольклорында чәчмә формадагы әсәрләр. "Ни өчен ни булган" төрендәге әкият-легендалар, аларның үзенчәлеге. Балалар фольклорының тел-стиль үзенчәлекләре.

53. Татар халык иҗатын укыту-тәрбия эшендә куллану, моны гамәлгә ашыру юллары.

54. Фольклор һәм язма әдәбиятның үзара мөнәсәбәте һәм бер-берсенә йогынтысы.

### 7.1. Основная литература:

1. Бакиров М.Х. Татар фольклоры. Югары уку йортлары өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2008. - 260 б.

2. Коваленко С.В. Мифы и сказки как система исторических свидетельств о происхождении русского этноса [Электронный ресурс] / Коваленко С.В. - М. : ФЛИНТА, 2016. - http://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785976527812.html

3.Тулякова Е. И., Плохотнюк, Т. Г. Устное народное творчество. Ч. 1 [Электронный ресурс] : учеб. пособие : в 4 ч. Ч. 1 / Т. Г. Плохотнюк, Е. И. Тулякова. - 2-е изд., стер. - М. : ФЛИНТА, 2012. - 46 с. - ISBN 978-5-9765-1513-0 http://znanium.com/bookread2.php?book=456358

4. Хроленко А.Т. Введение в лингвофольклористику [Электронный ресурс] / Хроленко А.Т. - М. : ФЛИНТА, 2016. - http://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785976508378.html

### 7.2. Дополнительная литература:

1. Плохотнюк Т.Г.Устное народное творчество [Электронный ресурс] / Плохотнюк Т.Г. - М. : ФЛИНТА, 2017. - http://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785976515154.html

2. Погребная Я.В. Актуальные проблемы современной мифопоэтики [Электронный ресурс] : учеб. пособие / Погребная Я.В. - 2-е изд., перераб., доп. - М. : ФЛИНТА, 2016. - http://www.studentlibrary.ru/book/ISBN9785976511354.html

3. Язык фольклора [Электронный ресурс] : хрестоматия / сост. А. Т. Хроленко. - 3-е изд., стер. - М.: Флинта, 2012. - 224 с. - ISBN 978-5-89349-706-9.// http://znanium.com/bookread2.php?book=490423

### 7.3. Интернет-ресурсы:

Университетская энциклопедия - www.wikipedia.ru

ЭБС "Знаниум" - http://znanium.com/

ЭБС "Консультант студента" - http://www.studentlibrary.ru

Электронные библиотека и материалы сайта КФУ - www.ksu.ru

Электронные словари - www.slovari.ru

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Татарское устное народное творчество" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе "ZNANIUM.COM", доступ к которой предоставлен студентам. ЭБС "ZNANIUM.COM" содержит произведения крупнейших российских учёных, руководителей государственных органов, преподавателей ведущих вузов страны, высококвалифицированных специалистов в различных сферах бизнеса. Фонд библиотеки сформирован с учетом всех изменений образовательных стандартов и включает учебники, учебные пособия, УМК, монографии, автореферáты, диссертации, энциклопедии, словари и справочники, законодательно-нормативные документы, специальные периодические издания и издания, выпускаемые издательствами вузов. В настоящее время ЭБС ZNANIUM.COM соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Компьютерный класс (стандартная комплектация для практических занятий и самостоятельной работы), доступ к сети Интернет.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 45.03.01 "Филология" и профилю подготовки Прикладная филология: татарский язык и литература, журналистика .

Автор(ы):
Замалиева Л.Ф. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Закирзянов А.М. ____________________
"__" _________ 201 __ г.